**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2828**
**06.05.2024**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 10 пункты (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы Карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру үзенчәлекләренә 1 нче кушымта), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2024 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2024 елның 12 мартындагы 174/пр номерлы приказы, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» КП экспертиза-консультация советы тарафыннан үткәрелгән тикшеренү нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләргә торак урыннар сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2024 елның икенче кварталына 85 522 сум күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                                   Ф.Ш. Салахов